*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*




# Чишмә башы

*Март, 2025 ел*

*№ 5*

*Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар*



## Халык сынамышлары

- Яз көне эретмичә озак туңдырып торса, җәй коры була.
- Яз көне агачлар бөреләрен астан яра башласа, яз тиз килә.
- Кара карга килгәч, бер айдан  кар китәр.
- Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.
- Елгалар язын боздан тиз әрчелсә, ашлык уңар.
- Су ташуы куәтле булса, ашлык яхшы булыр.
- Язын иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы булыр.
- Аккош яз көне иртә күренсә, салкын булыр, кар тиз китмәс.
- Язын сыерчык иртә килсә, көннәр җылы булыр.

## Мәкальләр

- Язгы көн ел туйдыра.
- Яз сөрсәң, көз урырсың.
- Язгы хезмәт – көзге хөрмәт.
- Язның байлыгы – кояш,
  Көзнең байлыгы – уңыш.
- Бер көн алдан чәчсәң,
  Бер атна алдан урырсың.
- Ни чәчсәң, шуны урырсың.






### Яз килә.

Яз килә ич, яз килә!
Яз тәрәзәдән керә.
Яз керә ишекләрдән.
Язның килүен кем генә
Калды икән ишетмәгән?
Яз кошлар белән килә,
Яз елмая,яз көлә.
Яз тамчы булып тама.
Урамнарга сыя алмыйча
Гөрләвек булып ага.
Урамдагы гөрләвектә
Көймәләр йөздерәбез.
Без үзебез зурлар инде,
Нәни эне- сеңелләрне,
Яз кояшында җылытып,
Тизрәк үстерәбез!

Гөлчирә Нәҗметдинова



## **“Кадерле әнием”**

Дөньяда иң матур сүз - ул Әни!

Дөньяда иң татлы сүз - ул Әни!

Дөньяда иң изге сүз –ул Әни!

Дөньяда иң затлы сүз –ул Әни!



7 март көнне безнең балалар бакчасында 8 Март Халыкара хатын-кызлар көненә багышланган “Кадерле әнием” бәйрәме булып үтте. Балалар бәйрәмгә тырышып әзерләнделәр. Күңелгә үтеп кererлек җырлар җырладылар, матур биюләр биеделәр,әниләр белән бергә уеннарда катнаштылар.Яз кызы бәйрәмгә килгәч тагын да күңеллерәк булды. Яз кызына балалар әниләренең исемнәрен татарча матур итеп әйтеп күрсәттеләр.Зурлар һәм кечкенәләр төркеме белән оештырылган бәйрәм бик күңелле узды. Бәйрәм азагында балалар әниләргә һәм әбиләргә үз куллары белән ясалган бүләкләр тапшырдылар. Кадерле кешеләребезне яратыйк, хөрмәт итик. Ходай сезне үз рәхим - шәфкатеннән ташламасын, теләкләрегезне тормышка ашырырга ярдәм итсен, өстәлләрегез мул, аш – суларыгыз тәмле, көннәрегез ямьле булсын!

I категорияле тәрбияче Гафурова Рафия Ансар кызы














Әниләребезнең күңел җылысы биреп эшләнгән
**“Әниемнең алтын куллары”** кул эшләре.



**Балаларның, тәрбиячеләрнең уңышлары**






















## “Профсоюз җыелышында чыгыш ясадык”

Наласа балалар бакчасы Наласа урта мәктәбе профсоюз оешмасы белән тыгыз элемтәдә эшли. Шул уңайдан 21 нче март көнне мәктәп белән берлектә профсоюз җыелышы булды. Балалар бакчасы мөдире Гафурова Эльмира Рашат кызы чыгыш ясады. Профсоюз оешмасы белән берлектә коллектив килешүе нигезендә максатчан эш алып барылуы,профсоюз оешмасы членнарын һәм ветеран хезмәткәрләрне котлап открыткалар тапшырылуы һәм бәйрәмнәрдә бакча коллективының читтә калмавы турында әйтелде.Хезмәткәрләрнең сәламәтлекләрен ныгыту максатыннан төрле санаторияләрдә ял итеп кайтулары турында да сөйләнелде. Профком оешмасы тарафыннан оештырылган төрле спорт ярышларында алдынгы урыннар алулары һәм актив катнашып килүләре турында да әйтелде.

Профсоюз оешмасының эшен оештыручы төп документ - коллектив килешүе. Коллектив килешү, хезмәткәрләрне өстәмә ташламалар,түләүләр белән тәэмин итәргә,хезмәт шартларын яхшыртуга һәм сакларга мөмкинлек бирә. Безнең Коллектив килешүенә 2025 нче елда өстәмәләр кертелүен мәшгульлек үзәгендә,район мәгариф идарәсенә профком тарафыннан регистрация узып 2026 нче елга кадәр кабул ителүе әйтеп үтелде.  Профсоюз оешмасы җитәкчелеге хезмәткәрләрне игътибарсыз калдырмый алдагы көннәрдә дә шулай булыр дип ышанып калабыз.





## “ Үсентеләр бизи тәрәз төбен ”













### Хәрби-спорт уены "Аҗаган".

Балалар бакчабызда "Аҗаган" хәрби-спорт бәйрәме узды. Бу мәктәпкәчә яшьтәге балаларда, патриотлык хисе, үз Ватаныңа хөрмәт, мәхәббәт, горурлык хисе тәрбияли. Күңелле вакыт уткәрү, үз сәләтләренне күрсәтү һәм файдалы күнекмәләр алу өчен менә дигән мөмкинлек. Уен барлык балаларны берләштерә, намуслылык, гаделлелек, команда белән бергә эшләргә өйрәтә.






**“Хуш киләсең, Нәүрүз!”**

Март ае- яз башы,бик матур ай.Бу ай яңа елның беренче ае булып йөргән. Язның көн белән төн тигезләшкән вакыты 21- 22 март - Нәүрүз бәйрәме буларак билгеләнеп үтелгән. Нәүрүз - язны каршылап,язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул . Бүген Наласа мәдәният йортында бик матур итеп Нәүрүз бәйрәме үткәрдек. Бәйрәмне мәдәният хезмәткәрләре Наласа балалар бакчасының өлкән төркем балалары һәм башлангыч класслар белән берлектә үткәрде.Нәүрүз бәйрәме концерт номерлары,уеннар, табышмак- сынамышлар, җырлы- биюле уеннар белән үрелеп барды.Бәйрәм мөбарәк , илләребез тыныч, ризыкларыбыз мул булсын!





















## “Авылыбыз шагыйрәсе Гөлчирә апа Нәҗметдинованың туган көне.”



### Кадерле Гөлчирә апа!

Сезне кояш нурлары ак карларны, пакь җаннарны җылыткан көндә, якты дөньяга килгән иң олуг бәйрәмегез, туган көнегез белән тәбриклибез. Дөньяның саф һавасын сулап, ризыкларын татып, гүзәллеген күреп, балаларыгыз,туганнарыгыз белән бергә гомер кичерүегезне теләп калабыз. Ходай тәгалә сезнең шул бәхетләрегезгә өстәп сәламәтлек бирсен. Иҗат чишмәгез саекмасын, матур шигырьләр белән балаларны сөендереп торырга насыйп булсын.

Гөлчирә Мәхмүт кызы Нәҗметдинова 1959 елның 25 мартында Арча районы Наласа авылында дөньяга килә.Мәктәп елларыннан ук Гөлчирә апа иҗатка тартыла ,хыялы журналистлык һөнәре буенча укырга керү була.Әмма язмыш дигәннәре аны 10 сыйныфны тәмамлауга колхозда хисапчы итеп эшләтә башлый. Гөлчирә Нәҗметдинова 1987 елдан Наласа авылы китапханәсе мөдире булып хезмәт куя. Читтән торып Алабуга культура агарту техникумын тәмамлый. Аның шигырьләре район, республика газета –журналларында дөнья күрә, Казнның 1000 еллыгы уңаеннан Санкт –Петербургта нәшер ителгән “Сказание о Казани” шигырьләр җыентыгында Лилия Насыйбуллина тәрҗемәсендә ике шигыре, “Невский проспект”журналында әсәрләре басыла.

Гөлчирә Нәҗметдинова – дүрт шигырь җыентыгы һәм шактый гына җырлар авторы да.







### *“Дүрт фасылы туган ягымның.”*

*Туган якның салкын кышларына,*
*Ап-ак карларына сокланам.*
*Тәрәзәдә нинди матур бизәк!*
*Исем китеп карыйм мин һаман.*
*Ә язларын гөрләвекләр ага,*
*Кошлар кайта туган якларга.*
*Түбәләрдә озын боз сөңгесе-*
*Бигрәк сихри шундый чакларда.*

*Җәйләрендә җиләк исе аңкый.*
*Чәчәк исе, татлы бал исе.*
*Хәтфә кебек үлән өсләрендә*
*Килә туйганчы бер ауныйсы.*
*Ә аннан соң алтын көзләр килә:*
*Бигрәк матур, карап син соклан.*
*Бик бай бит көз:алма, гөмбә, кишер...*
*Рәхәтләнеп сыйлан син, туктап.*

*Минем туган ягым бигрәк гүзәл:*
*Кышы, язы, җәе, көзләре...*
*Һәр фасылы бер-бер артлы йөгерә*
*Матурланып, гел дә үзгәреп.*

***ГөлчирәНәҗметдинова***

***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Гафурова Р.А., Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары***: *Хөсәенова Р.Н., Шагиева А.К., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР, Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*